Халык жыены карары

№ 1 20.11.2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге составына керүче Зур Сукаеш
авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары», Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» нигезендә 17 ноябрь 2019 елда узган халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «Сез 2020 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәннәрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зур Сукаеш авылында юлларны кардан чистарту;
- Зур Сукаеш авылында җәй көне территорияне чабу;
- Зур Сукаеш авылында Яшьләр урамы белән Бакчалы урамын тоташтырган тыкырык юлын щебенка белән чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Бэйрэм чараларын оештыру һәм уздыру өчен бүләкләр алу;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру.

«Эйе» «Юк».

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 314 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 216 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 216 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге составына кергән Зур Сукаеш авылында узган халык җыенын халык җыены утте һәм халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һэм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 150 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнэлдерергэ:

- Зур Сукаеш авылында юлларны кардан чистарту;
- Зур Сукаеш авылында җәй көне территорияне чабу;
- Зур Сукаеш авылында Яшьләр урамы белән Бакчалы урамын тоташтырган тыкырык юлын щебенка белән чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Бэйрэм чараларын оештыру һәм уздыру өчен бүләкләр алу;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы: З.Җ.Закирова